**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 12 » ноябрь 2015 ел** **№ 10**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Иске Айван авылында 140 га мәйданлы территорияне җентекле планлаштыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, территориянең ныклы үсешен тәэмин итү максатларында, территориянең капиталь төзелеш объектлары, җир кишәрлекләре чикләре урнашкан җир кишәрлекләре, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының 2015 елның 14.09.2015 «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Иске Айван авылындагы 140 гектарлы террриториторияне җентекләп планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә Арча шәһәре Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Иске Айван авылында 140 га мәйданлы территорияне җентекләп планлаштыру проектын расларга.

2. Әлеге карарны 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында

(http:pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Карар рәсми басылып чыкканнан бирле үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев